# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

## Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Рус Наратлысы торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында

2023 елның 18 октябре № 2

Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә шушы сорау буенча 11 сәгать 00 минутта 2023 елның 18 октябрендә узган гражданнар җыены беркетмәсе төзелде: «2024 елда Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Рус Наратлысы торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән, I группа инвалидларыннан, күп балалы гаиләләрдән һәм мобилизацияләнгән кешенең гаиләсеннән тыш, 500,00 сум күләмендә үзара салым кертергә риза буласызмы?

1. Рус Наратлысы торак пунктында юлларны механикалаштырып җыештыру;
2. смета документларын әзерләү;

«ӘЙЕ» « КАРШЫ»

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә **11** кеше кертелгән, гражданнар җыенында тавыш бирүдә **7** кеше катнашты, бу **63,6%** тәшкил итә.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучылар өчен түбәндәге урыннар билгеләнде:

«ӘЙЕ» позициясе өчен җыенда **7** кеше тавыш бирде;

«КАРШЫ» позициясе өчен җыенда катнашкан **0** кеше тавыш бирде

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең Рус Наратлысы торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.
2. 2024 елда үзара салым акчаларын яшәү урыны буенча теркәлгән һәм Татарстан Республикасы Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлеге территориясендә Рус Наратлысы торак пунктында даими яшәүче һәр балигъ булган, I группа инвалидларыннан, күп балалы гаиләләрдән һәм мобилизацияләнгән кешенең гаиләсеннән тыш 500,00 сум күләмендә кертергә.

3.Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

1. Рус Наратлысы торак пунктында юлларны механикалаштырып җыештыру;

2.смета документларын әзерләү;

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштыру (http://pravo.tatarstan.ru Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Зеленодольск муниципаль районы сайтында (http://zelenodolsk.tatarstan.ru) «Интернет» мәгълүмати-телекоммуникация челтәрендә, шулай ук Зеленодольск муниципаль районы Рус Әҗиле авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында түбәндәге адреслар буенча: Рус Әҗиле авылы, Центральная урамы, 1 йорт (җирлек хакимияте бинасы), Карашам авылы, Новая урамы, 27 йорт (мәдәният йорты бинасы).

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Гражданнар җыенында
рәислек итүче Г.Ф.Семахина